# ЧИШМӘ БАШЫ

№7, Май, 2025

МБГБУ «Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”











| ЭКОЯЗ | 9 МАЙ – ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ | 24 МАЙ – ЧЫГАРЫЛЫШ КИЧӘСЕ |
|---|---|---|

**ГАЗЕТАБЫЗНЫҢ МАЙ АЕ САНЫНДА:**

- 1 Май – Яз һәм хезмәт бәйрәме.
- Санитар икеайлык – “ЭКОяз – 2025”
- 9 май – Җиңү бәйрәме
- 19 май – Пионерлар көне
- 24 май– Соңгы кыңгырау бәйрәме

## МАЙ – ЯЗ ҺӘМ ХЕЗМӘТ АЕ.




1 май – Яз һәм хезмәт бәйрәме.

Көн саен үзенең хезмәте белән Ватанын һәм гаиләсен чәчәк аттыручы бөтен халык бәйрәме. Өлкән буын өчен 1 Май элеккечә пролетар бердәмлекне гәүдәләндерә, ә яшьләр өчен –табигать һәм кешелек көчен тудырган язгы чәчәк ату чоры.

## Татарстанда традицион санитар-экологик икеайлык дәвам итә.



Мәктәбебездә язгы эшләр дәвам итә.



Сарай-Чокырча башлангыч мәктәбе укучылары "Ашыт" дәүләт табигать тыюлыгы белгечләре Рәшит Зиннур улы Әхмәтҗанов һәм Габдрахманова Гөлнара Ильяс кызы белән очраштылар. Очрашу балаларда әйләнә-тирә табигатькә һәм хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү, экология белән кызыксынуны үстерү максатында үткәрелде.



«Яшьләр һәм балалар» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында һәм «экологик иминлек» илкүләм проектына ярдәм йөзеннән Татарстан Республикасында «ЭКОяз-2025»экологик конкурсы узды "




# 9 май – Җиңү бәйрәме

**9 майда Русиядә бөтенхалык бәйрәме** – 1941-45 елгы Бөек Ватан сугышында Җиңү көне билгеләп үтелә. Бөек Ватан сугышы кешелек тарихында иң зур кораллы бәрелешләрдән санала.







Бөек Җиңүнең 80 еллыгы алдыннан Арча МР башлыгы, Урта Курса авыл җирлеге башлыгы, Юнармия отряды әгъзалары һәм «Җиңү Волонтерлары» хәрәкәте активистлары тыл ветераннары янына килеп сугыш елларындагы фидакарь хезмәте өчен шәхсән рәхмәтләрен белдерделәр.






6 көнне май көнне Алан башлангыч мәктәбендә Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган митинг булып узды. Бүгенге яшь буын өчен ул - Хәтер көне. Укучылар сугыш темасына багышланган җырлар җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Сугышта һәлак булган авылдашлар истәлегенә венок, чәчәкләр куйдылар. Һәм аларның рухларына тынычлык теләп бер минут тын алдылар.

6 нчы май көнне Корайван авылында Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган бәйрәм тантанасы булып узды. Тантананы авыл җирлеге башлыгы Вафина Рәмзия Рамазан кызы башлап җибәрде. Ул авылдашларны бәйрәм белән котлады, хәзерге көннәрдә дә Бөек Җиңүнең әһәмияте турында сөйләде. Аннары сүз авылдашыбыз “Арча хәбәрләре” газетасы журналисты Фәттахов Ильяс Сәхәп улына бирелде. Корайван башлангыч мәктәбе укучылары авылдашларына Бөек Ватан сугышына багышланган җырларын, шигырьләрен бүләк иттеләр. Урта Курса мәктәбе укучылары сугышта һәлак булган авылдашларыбыз истәлегенә куелган һәйкәлгә венок куйдылар, кунаклар чәчәкләр салдылар. Көннәребез якты, күгебез һәрвакыт аяз булсын дигән теләк белән бәйрәм тәмамланды.




7 май көнне Сарай-Чокырча Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган тантаналы митинг узды. Тантанада махсус хәрби операциядә һәлак булган Валиев Айнур истәлегенә мемориаль такта ачылды








8 майда Урта Курса авылында Бөек Ватан сугышы Җиңүнең 80 еллыгына багышланган тантаналы митинг, «Үлемсез полк” акциясе узды. Катнашучылар геройларны искә алдылар, мемориалга чәчәкләр салдылар һәм тынычлык һәм ирекне саклап калучыларның батырлыкларын искә алдылар. Митингтан соң мәктәп укучылары һәм укытучылары әзерләгән бәйрәм чарасы узды. Балалар сугыш еллары җырлары, шигырьләр һәм театраль рәсемнәр белән әдәби-музыкаль композиция тәкъдим иттеләр.

**Кирәкми безгә сугыш (Ә.Исхак)**

**Кирәкми безгә кан кою,**
**Кирәкми безгә сугыш!**
**Безнең теләк якты, матур,**
**Тыныч хезмәт һәм тормыш.**

**Илебез зур, җиребез киң,**
**Хисапсыз байлык бездә!**
**Җир өстендә, җир астында,**
**Тауларда һәм диңгездә.**

**Без үз кулларыбыз белән**
**Төзибез гүзәл тормыш.**
**Без – тыныч ил төзүчеләр,**
**Кирәкми безгә сугыш!**

**“Безгә тынычлык кирәк”**
**(Әхмәт Ерикәй)**

**Шаулый урман, гөрли болын,**
**Яфрак яра тал тирәк,**
**Яшел бакча төзү өчен,**
**Безгә тынычлык кирәк.**

**Тормышны, җирне ярату-**
**Безнең беренче теләк,**
**Зур заводлар салу өчен,**
**Безгә тынычлык кирәк.**




16 май көнне Г.Курсави исемендәге лицей базасында районкүләм "Мин - Арча баласы" проекты рамкаларында асфальтта рәсем ясау конкурсы узды. Әлеге конкурста катнашып, 3 нче сыйныф укучысы Насыйбуллина Әминә, 4 нче сыйныф укучысы Бикбаева Зәринә 2 нче урыннарны, 7 нче сыйныф укучысы Бикбаева Руфинә 1 нче урынны алдылар. Укучылар иҗади эшләрендә Арчанын истәлекле урыннарына, Бөек Җиңүнең 80 еллыгына, юл йөрү кагыйдәләренә багышланган темаларны яктырттылар.

19 май – Пионерия көне.

19 май – Пионерия туган көн. В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасы 1922 елның 19 маенда төзелгән.






Пионер, комсомол, коммунист…
Пионер — беренче дигән сүз.
Пионерлар — билгесезлеккә юл салучылар, курку белми алдан баручылар. Пионерия оешмасы яшь буынны тәрбияләүнең иң мөһим чарасы булып торды. Күпме гомер үткән, күпме сулар аккан. Кайчандыр шаулап-гөрләп яшәгән пионерия инде тарихта гына калды. Шул уңайдан безнең укучылар матур чарада булдылар, учак янында төрле уеннар уйнадылар, җырлар җырладылар, һәм бию биеделәр.

# Укучылар иҗаты

Килеп җитте көткән җәйләр
Рәхәт бигрәк.
Кояш көлә, чәчәк үсә
Тагын ни кирәк?
Яшел чирәм арасында
Җырлый чикерткә.
Җәйнең рәхәтлеген, димәк,
Ул да сизенә.
Җәйләр җитте, рәхәтләнеп,
Җиләк җыярбыз.
Арсак, бераз ял итик дип
Суга чумарбыз.

**Шакирова Сәйдә, 3 класс**
**Корайван мәктәп укучысы.**

Ямьле җәй житкәч, яшел
хәтфәдәй болын, аланнар;
Аларны күреп, күңел сөенә.
Җиргә ямь өстәп, чут-чут
сайрыйлар нәни кошчыклар,
Аларны тыңлап, күңел сөенә.

**Фаттахов Айзат, 1 класс**
**Корайван мәктәп укучысы.**



Шулай ук укучыларыбыз кул эшләнмәләре белән дә кызыксыналар.


Алан башлангыч мәктәбендә “Җәй нинди була ул?” темасына укучылар белән урамда кызыклы рәсем дәресе үткәрелде.



## Мәктәпләрдә “Соңгы кыңгырау” чыңлый

Соңгы кыңгырау – дәресләр, күңелле тәнәфесләр һәм укытучыларның биргән белеме һәм тормыш күнекмәләре белән үрелеп баручы балачак белән хушлашу символы. Нәкъ менә “Соңгы кыңгырау” бәйрәме безнең күңелләребездә укытучылар, сыйныфташлар һәм мәктәп еллары турында якты хатирә булып сакланып калучы бәйрәм. Урта Курса мәктәбенең 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен 24 нче май көнендә соңгы кыңгырау чыңлады. Әлеге вакыйгага багышланган линейка бик җылы бәйрәм рухында үтте, чөнки чыгарылыш сыйныф укучыларын бу кыңгырау соңгы тапкыр дәрескә чакырды. Алда әле имтиханнар көтелүгә карамастан, соңгы кыңгырау – озак елларга хәтердә сакланып калачак олы тормышка аяк басуның беренче адымы.











Сарай – Чокырча  башлангыч мәктәбендә 4 сыйныф өчен соңгы кыңгырау чыңлады.

Корайван  башлангыч мәктәбендә дә 4 сыйныф өчен соңгы кыңгырау чыңлады.

## Ял сәгатьләрендә







**Сәхифәне** ***әзерләделәр***: башлангыч сыйныф укытучылары Шакирҗанова А. И., Сәмигуллина Р.Р.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:** 422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт
**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru

**Социаль челтәр бите:** https://vk.com/77arsk_srkorsa